| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **КАРАР**<br>**04.02.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 168** |
|---|---|---|

Зеленодольск шәһәре территориясендә «Торак-2020» янгын-профилактик операциясе үткәрү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге123-ФЗ номерлы Федераль законы таләпләре таянып, Зеленодольск шәһәре территориясендә янгыннарда кешеләрнең гомере өзелүе белән имин булмаган хәл аркасында, торак фондта янгыннарны кисәтү һәм аларда кешеләр һәлак булу максатыннан , шулай ук ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге һәм ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эше идарәсенең 10.01.2020, 17.01.2020 язган хатларына нигезләнеп Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елда Зеленодольск шәһәре территориясендә «Торак-2020» янгын – профилактик операциясе үткәрергә.
2. Торак фондта янгын-профилактика һәм агитация эшләре алып бару өчен түбәндәге составта профилактик төркем төзергә:

– «ТР ЗМР ТКХ департаменты» МБУнең әйдәп баручы белгече Камаев Сергей Александрович һәм хезмәт күрсәтүче оешмалар вәкилләре;

– ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге хезмәткәре (килешү буенча)

– Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлек хезмәткәре (килешү буенча);

– ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Янгынга каршы федераль хезмәтнең 8нче федераль янгын сүндерү-коткару отряды хезмәткәре (килешү буенча);

– ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге хезмәткәрен (килешү буенча);

– ЗМР Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге хезмәткәре;

– «Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыяте» ТРО Зеленодольск районара бүлеге хезмәткәре (килешү буенча);

– «Зеленодольскгаз» эксплуатация-житештерү идарәсе хезмәткәре (килешү буенча);

– «Жилэнергосервис–Зеленодольск» ЖЧЖ һәм торак фондта электр хуҗалыгына хезмәт күрсәтүче башка оешмалар (килешү буенча) хезмәткәрләре.

3. Зеленодольск муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлекләре Башлыкларына тәкъдим итәргә:

әлеге карар нигезендә, үз җирлекләре территориясендә «Торак-2020» янгын – профилактика операциясе үткәрү турында карар кабул итәргә һәм операция кысаларында эшне оештырырга;

«Торак-2020» янгын-профилактик операциясен үткәрү кысаларында алга таба эшләү өчен торак секторында һәм профилактик төркемнәр составына кертелгән тиешле оешмаларның вазыйфаи затларында профилактик эш оештыру өчен җирлекләрнең җаваплы вазыйфаи затларын фамилиялап расларга;

№1 кушымта нигезендә «Торак-2020» операциясе кысаларында торак фондында һәм торак пунктларда агитация-профилактик чаралар үткәрү өчен торак секторның профилактик төркемен тикшерү графигын эшләргә һәм расларга;

журналда (2 нче кушымта) язып һәм белешмәлек (4 нче кушымта);тапшыру белән янгынга каршы инструктаж үткәрүне исәпкә алуны оештырырга;

айның соңгы сишәмбесендә ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлегенә белешмәләрне 3 нче кушымта нигезендә (Р. Р. Ардыхановка) электрон документ әйләнеше системасы аша яки e-mail аша тапшырырга: ogpn-zmr@yandex.ru;

21.02.2020 елга кадәр ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге шәһәр (авыл) җирлекләрендә янгын-профилактика операциясен үткәрү турында кабул ителгән карарларның күчермәләрен эштә исәпкә алу өчен бирергә.

4. ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге башлыгы Р. Р. Ардыхановка ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 8 Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең федераль янгын сүндерү-коткару отряды башлыгы З. М. Хәлиуллин белән бергә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә :

авыл җирлекләре территорияләрендә «Торак-2020» янгын – профилактик операциясен үткәрү турында карарлар әзерләүдә шәһәр (авыл) җирлекләре башлыкларына методик ярдәм күрсәтү;

оператив профилактик төркемнәргә методик ярдәм күрсәтергә, торак сектордагы биналарга һәм корылмаларга куела торган янгын куркынычсызлыгының төп таләпләрен һәм профилактик чаралар үткәрү тәртибен аңлатырга, шулай ук күрсәтелгән төркемнәрне халык арасында таралу өчен көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү буенча белешмәлекләр белән тәэмин итәргә.

5. ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы Л. В. Билалиевага түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге ,ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 8 Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең федераль янгын сүндерү-коткару отряды хезмәткәрләре белән бергә күп балалы гаиләләр, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм патронаж исәптә торучы затларның яшәү урыннарын һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозуны профилактикалау һәм янгынга каршы инструктажлар үткәрү максатыннан тикшерү үткәрергә;

республика программалары кысаларында билгеләнгән автоном янгын хәбәрчеләренең төзеклегенә мониторинг ясарга.

6. «ЗМР ТКХ департаменты» МБУ җитәкчесе И. В. Грузковка:

ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге белән берлектә оператив профилактик төркем эшен оештырырга;

халык арасында почта элемтәсе, торак оешмалары, халыкны социаль яклау хезмәткәрләре, полициянең участок уполномоченныйлары, ирекле янгын җәмгыяте әгъзалары мөмкинлекләреннән файдаланып, янгынга каршы тематикага (белешмәлекләргә, мәгълүмат кәгазьләренә) агитация һәм пропаганда материаллары таратуны оештырырга;

хезмәт күрсәтүче оешмалар белән берлектә янгын гидрантларының, янгынга каршы су белән тәэмин итүнең башка чыганакларының һәм аларга керү юлларының төзеклеген, шулай ук аларны вакытында кардан һәм боздан чистартуны тәэмин итәргә;

торак фондының янгынга каршы торышы турындагы мәгълүматны гомумиләштерүне һәм анализлауны оештырырга, айның соңгы сишәмбесендә ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге аша башкарылган эшләр турында доклад (№1 кушымта нигезендә) ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә (Р. Р. Ардыхановка) яки e-mail аша ЗМР Башкарма комитетына электрон документ әйләнеше системасы аша (№1 кушымта нигезендә) тапшырырга. : ogpn-zmr@yandex.ru

7. Шәһәр (авыл) җирлекләре башлыкларына, «ЗВКС» АҖ директоры А.Ф. Исмәгыйлевка, үз балансында тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары булган предприятие җитәкчеләренә әлеге чыганакларны төзек

хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә, аларны сафтан чыгармаска, аларны вакытында ремонтларга, кардан һәм боздан чистартырга киңәш итәргә.

8.ТРБ Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыятенең Зеленодольск бүлеге директоры Р.Г. Нурмөхәммәтовка торак фондта төтен юлларын һәм вентиляция каналларын чистарту һәм профилактик тикшерүләр үткәрүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

9. ЗМР башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары – мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьева барлык белем бирү учреждениеләрендә укучылар һәм аларның ата-аналары белән көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы мәсьәләсе буенча методик дәресләр үткәрүне оештырырга.

10. «ЗВКС» АЖ, «Зеленодольскгаз» ЭПУ, «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» ААҖ, «Жилэнергосервис-Зеленодольск» ҖЧҖ һәм торак фондына хезмәт күрсәтүче башка оешмалар җитәкчеләренә җылылык системаларын ремонтлау, тузган электр үткәргечләрне алыштыру һ. б. буенча социаль якланмаган халыкка адреслы ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

11. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына:

әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

торак секторда янгыннар белән оператив хәлләр, торак фондының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең проблемалы мәсьәләләре һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга.

12. « Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Торак-2019» янгын-профилактика операциясен уздыру турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 21 февралендәге 428 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

13. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А. В. Старостин

2 нче кушымта
РАСЛЫЙМ
... .авыл җирлеге Башлыгы
(БК җитәкчесе)

_________________ Ф. И. О.
"___" _________ 2020 ел

«Торак-2020» операциясе кысаларында авыл җирлегенең торак фондында һәм БК торак пунктларында агитация-профилактика чараларын үткәрү өчен торак секторның профилактик төркеме тарафыннан урап узу

**ГРАФИГЫ**

| № т/б | Торак пункт (урамнар, йортлар) | Чараны үткәрү датасы | Җаваплы вазыйфаи зат | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| **Село/Авыл ……** | | | | |
| 1. | Үзәк | февраль | | |
| 2. | | | | |
| 3. | | | | |
| 4. | | | | |
| 5. | | | | |
| 6. | | | | |
| 7. | | | | |
| **Деревня//Авыл …..** | | | | |
| 8. | | | | |
| 9. | | | | |
| 10. | | | | |
| 11. | | | | |
| 12. | | | | |
| 13. | | | | |
| 14. | | | | |

«Торак-2020» операциясе кысаларында»

**ЯНГЫНГА КАРШЫ ИНСТРУКТАЖ ҮТКӘРҮНЕ ИСӘПКӘ АЛУ ЖУРНАЛЫ**

| № т/б | Инструкция үтүченең ФИО | Инструкция үтүченең тору адресы | Белешмәлек тапшыру турында билге | Инструкция-үткәрүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |
| 3. | | | | |
| 4. | | | | |
| 5. | | | | |
| 6. | | | | |
| 7. | | | | |
| 8. | | | | |
| 9. | | | | |
| 10. | | | | |
| 11. | | | | |
| 12. | | | | |
| 13. | | | | |
| 14. | | | | |
| 15. | | | | |